ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.08.2025 1267 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләр куллануны (фейерверк атуны) тәртипкә салу чаралары турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1710 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карарының 56 пункты нигезендә, Яр Чаллы шәһәре Кама транспорт прокуратурасының протестын караганнан соң Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләр куллануны (фейерверк атуны) тәртипкә салу чаралары турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1710 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча оештыру-техник чаралар комплексы эшләнгән, махсус сәхнә эффектлары, профессиональ пиротехник эшләнмәләр һәм ут эффектлары кулланудан тыш, теләсә кайсы функциональ билгеләнештәге урыннарда, биналарда һәм корылмаларда;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Лист согласования к документу № 1267 от 04.08.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 06.08.2025 16:29

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>06.08.2025 - 21:34 | - |